КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 13 декабрь г.Казань № 1214

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы турында» 2009 ел, 31 декабрь, 920 нче карарына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Илкүләм проектларны контрольдә тоту» юнәлеше буенча Татарстан Республикасының мәгълүмат-аналитика системасын тәҗрибә рәвешендә файдалану чорында аның эшләвенә карата вакытлыча регламентны раслау турында» 2020 ел, 25 июнь, 524 нче карары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы турында» 2009 ел, 31 декабрь, 920 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 17 август, 712 нче; 2013 ел, 30 сентябрь, 701 нче; 2015 ел, 27 август, 625 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1317 нче; 2021 ел, 6 сентябрь, 818 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасының «Контроль» модуле эшләве тәртибен.»;

түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$. Система операторы Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасының «Электрон документлар әйләнеше»

модуленә үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты белән килештерергә тиеш.»;

әлеге карарга Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасының «Контроль» модуле эшләве тәртибен (карарга теркәлә) өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Илкүләм проектларны контрольдә тоту» юнәлеше буенча Татарстан Республикасының мәгълүмат-аналитика системасын тәҗрибә рәвешендә файдалану чорында аның эшләвенә карата вакытлыча регламентны раслау турында» 2020 ел, 25 июнь, 524 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин